# ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ВАХИТ ХАКОВНЫҢ ОЛЫ МИРАСЫ

*Аскарова Л. Р.*

# NATIVE LANGUAGE AND HERITAGE OF VAKHIT KHAKOV

*Askarova L. R.*



Галим китәр – сүзе калыр, йөргән җирендә эзе калыр, ди татар халык мәкале. Мөхтәрәм укытучым, күренекле галим-телче Вахит Хөҗҗәт улы Хаковны искә алганда бу сүзләр гел күңелдә яңгырый. Вахит ага арабызда булмаса да, аның исеме бик еш телгә алына, хезмәтләре тел белеме өлкәсендә яңа фәнни эзләнүләр өчен нигез булып тора.

Татар телен яратып, аңлап, белеп һәм шул эшеннән тәм табып эшләгән галимнәрнең берсе – Вахит ага Хаков. Ул – дөньякүләм танылган тел белгече, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының атказанган профессоры, Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Гуманитар Фәннәр Академиясенең академигы, Австралиядәге «Җир шарында Гуманизм һәм Гаделлек өчен» дигән Халыкара Рыцарьлар Конфедерациясенең әгъзасы һәм башка бик күп мактаулы исемнәргә лаек бөек шәхес иде.

Вахит Хөҗҗәт улы – татар теле белеме өлкәсендә фундаменталь көч куйган шәхес. Аның хезмәтләре фәнни яктан тирән эчтәлекле, фактик материалга бай булулары белән аерылып тора, һәм хәзерге

көндә тел белеме өлкәсендә барган эзләнүләр өчен нигез вазифасын башкаралар. Вахит ага Хаков хезмәтләре татар теленең үткәнен барларга, бүгенгесен аңларга, киләчәк үсеш юлын фаразларга ярдәм итәләр.

Аның иҗади тырышлыгы, армый-талмый эзләнүләр алып баруы нәтиҗәсендә бүгенге культуралы җәмгыятьне татар теленең, татар мәдәниятенең әһәмиятен, безнең күпмилләтле мөхиттәге багъланышларын тирәнрәк аңлауга этәрә.

Биш яшеннән бабасы Габделхакның (ул Буа районының Күзби авылы мулласы була) китапханәсендә Кол Гали, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый китапларын укый башлый Вахит. Мәктәпкә кергәндә үк, булачак һөнәре кем булачагы ачыкланган була инде – этисе кебек мөгаллим булачак ул. Башта Күзбидә, аннан соң Килдураз урта мәктәбендә укыган чакта ук 1939–1941 елларда «Яңа юл», «Яшь ленинчы» һәм «Пионер каләме»нә мәкаләләр яза ул. 8нче сыйныфны тәмамлагач, Бөек Ватан сугышы башлана. Килдураз мәктәбе ябыла, Буага укырга барырга мөмкинлек булмый, Вахит колхозга эшкә керә. Авылның ирләре сугышта, этисе – Сиваш сазлыкларын кичкән гражданнар сугышы ветераны Хөҗҗәт абыйны да Бөек Ватан сугышына алалар. Вахит барлык яшьләр белән бергә окобын да казый, урман кисә, сугыш һөнәрләренә дә өйрәнә. 1943 елда 17 яше тулган Вахитны сугышка алалар. Буадан Казан аша туп-туры Монголиягә озаталар аны. Далада, суык землянкаларда солдат тормышы башлана. Бик күп сугышчылар көнбатыш фронтка җибәрүләрен сорыйлар, ләкин бу турыда авыз да ачтырмыйлар. Г. Шәрәфинең «Сусыз дәрья», И. Беляевның «Солдат төймәсе» романнарында мең чакрымнарга сузылган даланы һәм Гоби чүлен узу чагылыш тапкан.

Вахит 1949 елга кадәр Идел буе хәрби округында хезмәт итә. Туган ягына кайтып кергән Вахитны этисе китаплар тотып каршы ала: «Укуыңны дәвам итәргә кирәк, улым». Хәрби хезмәттән кайтып, педучилищега, аннан соң Казан дәүләт университетына укырга керә ул. Профессор Латыйф Җәләй җитәкчелегендә 1960 елда аспирантураны уңышлы тәмамлаганнан соң, Вахит ага кече фәнни хезмәткәр булып институтта кала. Озакламый Вахитны Казан дәүләт университетына ассистент итеп күчерәләр. Һәм менә 1960 елның октябреннән башлап аның киләчәк фәнни-педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге университет белән бәйләнгән була. В. Хаков 1961 елда XX йөз башында татар әдәби теле тарихы мәсьәләләренә багышланган кандидатлык диссертациясе яклый. 1964 елны Вахит Хөҗҗәтовичка доцент исеме бирелә. 1971 елда ул Алма-Ата шәһәрендә «Татар әдәби теленең һәм стильләрнең үсеш тарихы» дигән темага мең биткә якын күләмдәге докторлык диссертациясен яклый һәм филология фәннәре докторы дигән

дәрәҗә ала. Ә 1973 елда аңа профессор дигән исем бирелә. Шул еллардан татар теле кафедрасында җитәкчелек тә итә.

В.Х. Хаковның төп фәнни тикшеренү объекты – татар әдәби теле тарихы һәм татар теленең стилистикасы. Профессор Л. Җәләй җитәкчелегендә башланган эшне күп еллар дәвамында тагын да үстереп, В.Х. Хаков «Татар әдәби теле тарихы» фәненә нигез салучылардан санала. «Әдәби тел тарихы» фәне лингвистик һәм социологик юнәлештә әдәби телнең барлыкка килү һәм үсү кануннарын, төзелешен һәм алдагы үзгәрешләрне тарихи үсештә өйрәнә. Бу фәндә норма һәм стиль дигән ике зур төшенчә аерылып чыга. Әдәби телнең үсеше стильләр белән тыгыз бәйләнештә тора. Әдәби тел үзенә күп төрле сөйләм стильләрен берләштерә. Бу – әдәби телнең нигез ташы. В.Х. Хаков хезмәтләренең үзенчәлекле ягы да шунда, аларда әдәби тел нормаларының тарихи үсеше телдәге стилистик категорияләр белән тыгыз мөнәсәбәттә тикшерелә һәм бу борынгы чорларда ук иҗат ителгән язма истәлекләр нигезендә аерым чорларга бүленеп фәнни яктан дәлилләнеп бара. Димәк, әдәби тел тарихы аерым методлар, махсус анализлар белән эш итә. Боларның нигезендә телләрне тикшерүдә тарихи-чагыштырма метод һәм лингвостилистик анализ ята. Монографияләрдә автор төрле чорларда барлыкка килгән әдәби тел нормаларын сакланып калган кульязмалар һәм нәшер ителгән төрле жанр әсәрләре, стильләр нигезендә җентекләп тикшерелә.

1990 елларда татар телен латин графикасына күчерү турында сүз чыккач, эшкә тотынган галимнәрнең беренчеләреннән була Хаков. Аның йөз мең тираж белән чыккан «Телен белгән ил ачар» китабы – шуның ачык мисалы.

1993 елда басылып чыккан «Татар әдәби теле тарихы» монографиясендә галим беренчеләрдән булып татар әдәби теленең тарихы, аның нормалары һәм матур әдәбият стиле тикшерелә, шул рәвешле, татар матур әдәбият стиле тарихи аспектта тулаем өйрәнеп чыгыла.

В. Хаков татар әдәби теленең һәм функциональ стильләрнең барлыкка килүен чорларга бүлеп тикшерә, һәр чорга тарихи-лингвистик яктан характеристика бирә, язма әдәби стильне һәм халык сөйләмен барлыкка китерүче чараларны анализлый. 2003 елда басылган «Тел – тарих көзгесе» дигән монографиясендә татар әдәби теленең ерак гасырларга тарихы күз алдына килеп баса. Вахит Хаков, рун язуларын укый белүче галим буларак, борынгы төрки телнең фонетик, график, орфографик, лексик-семантик үзенчәлекләрен, ул чорда ук стильләрнең аерымлануын ачып бирә, аларны, тарихи – чагыштырма ысул кулланып, хәзерге татар теле белән чагыштыра. Бу монографиядә татар әдәби теленең үсешен чорларга бүлеп өйрәнү XX гасырны да үз эченә ала.

1996 елдан башлап Вахит Хаков Татар энциклопедия институтының тел һәм әдәбият бүлегендә фәнни консультант булып та эшләде. 30 ел буе «Тел күрке – сүз» исемле радиотапшыруны оештырып һәм алып баручы булып та хезмәт куя халкына Вахит ага.

2006 елда «Татар әдәби теле диахроник һәм синхроник аспектта» циклында чыккан хезмәтләрендә галим татар әдәби теленең периодларга бүленешен, аның традицияләрен, сөйләм һәм язма формаларын сурәтли. Бу хезмәт Татарстан Республикасының дәүләт премиясенә лаек була.

Вахит ага Хаковның йөрәге 2008 елның 20 июнендә тибүдән туктый. 1949 елдан бирле педагогик хезмәттә булып, гомеренең соңгы көненә кадәр университетта студентларга белем биргән Вахит аганың укучылары илебез буйлап таралган һәм шактые остазының эшен дәвам итә. Вахит Хаков күпләргә үрнәк булырлык галим, җәмәгать эшлеклесе, тирән фикер иясе булды. Халык Вахит Хаковның фәнни эшчәнлеген өйрәнеп һәм хөрмәт итеп яшәсә, милләтебезнең рухи офыклары киңәер.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков искиткеч зыялы галим иде. Безнең күңелләрдә ул һәрвакыт олы җанлы, сабыр, тирән белемле, хөрмәтле остазыбыз булып саклаdüнып.

**Сведения об авторе:** Аскарова Лилия Раисовна, научный сотрудник Центра регионоведения и социокультурных исследований Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: askaroval@mail.ru.

**Аннотация:** Статья посвящена памяти татарского языковеда, доктора филологических наук, профессора В. Х. Хакова (1926–2008), внесшего большой вклад в татарское языкознание. Указываются основные вехи жизни ученого, отмечаются наиболее известные его работы.

**Ключевые слова:** языкознание, стилистика, культура речи, татарский литературный язык.

**Abstract:** The article is dedicated to the memory of the Tatar linguist, doctor of philological sciences, professor V. Kh. Khakov (1926–2008), who made a great contribution to Tatar linguistics. The main milestones of the scientist's life are indicated, his most famous works are noted.

**Key-words:** linguistics, stylistics, speech culture, Tatar literary language.